Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы
карары

№ 4 20.10.2022

Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге
Татар Такталы торак пунктында 2023 елда үзара салым
кертү һәм куллану буенча гражданнар җыены
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАРЫ:

1. 2023 елда Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегенең Татар Такталы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенның 1нче этабын Татарстан Республикасы, Спас районы, Татар Такталы авыл мәдәният йорты бинасында 2022 елның 10 нчы ноябренә 14.00 сәгатькә билгеләргә.
2. 2023 елда Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегенең Татар Такталы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенның 2нче этабын Татарстан Республикасы, Спас районы, Татар Такталы авыл мәдәният йорты бинасында 2022 елның 11 нче ноябренә 14.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:
   “Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлегегенә кергән Татар Такталы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 нче группа инвалидлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән сез килешәсезме?:

- Татар Такталы торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам утларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Татар Такталы  авылында  юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы  авылында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык – майлау материаллары, МТЗ-82 тракторына запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Татар Такталы  торак пунктында чүплекләрне эттерү (чүп мәйданчыкларын карап тоту) (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Татар Такталы  торак пунктында бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү: Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне, Яңа ел (канцелярия товарлары, бүләкләр, сувенирлар сатып алу.);
- Татар Такталы торак пунктында янгын гидрантын алу һәм урнаштыру (контракт буенча эш өчен түләү);

“ӘЙЕ”                    “ЮК”

4. Әлеге карарны Аграмак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Аграмак авыл җирлегенең рәсми сайтында http:/ www. spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Аграмак авыл җирлеге башлыгы                Р.Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ